# ГРАЖДАННАР ЖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Балан-Бүләк авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

15 ноябрь 2024 ел №1

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Уставы нигезендә 2024 елның 15 ноябрендә түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гаражданнар җыенының протоколы төзелде:

«Сез, 2025 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, өлешчә мобилизацияләүгә чакырылган гражданнар, аларның гаилә әгъзаларыннан һәм хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән һәм махсус хәрби операциягә җибәрелгән гражданнардан, аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Балан-Бүләк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- Балан-Бүләк торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзекләндерү, ремонтлау, тоту (Ленин урамына вак таш сатып алу, ташу, салу, эш өчен килешү буенча түләү);
- Урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (лампалар, яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җайланмалар сатып алу һәм алмаштыру, Балан-Бүләк авылы урамнарын яктыртуны ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча хезмәтләре күрсәтү);
- Торак пункт территориясен төзекләндерү (тракторчыга механикалаштырылган кар җыю буенча хезмәтләр өчен түләү, торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге юлларны тоту буенча чит оешмалар хезмәтләре өчен түләү, килешү буенча эшләр өчен түләү, Балан- Бүләк торак пунктында үлән чабу хезмәтләре өчен түләү, корыган агачлардан һәм куаклардан чистарту, килешү буенча эш һәм хезмәт күрсәтүләргә түләү)

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия 71 гражданнар җыенында катнашучы теркәлгән, халык җыенында катнашып тавыш биргән гражданнар саны 37.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«РИЗА» позициясе өчен 37, «КАРШЫ» » позициясе өчен 0 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Балан-Бүләк торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре – гамәлдә (дөрес) дип танырга.

2. Түбәндәге сорау буенча карарны кабул ителгән дип танырга:

«Сез, 2025 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, өлешчә мобилизацияләүгә чакырылган гражданнар, аларның гаилә әгъзаларыннан һәм хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән һәм махсус хәрби операциягә җибәрелгән гражданнардан, аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Балан-Бүләк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- Балан-Бүләк торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзекләндерү, ремонтлау, тоту (Ленин урамына вак таш сатып алу, ташу, салу, эш өчен килешү буенча түләү);
- Урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (лампалар, яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җайланмалар сатып алу һәм алмаштыру, Балан-Бүләк авылы урамнарын яктыртуны ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча хезмәтләре күрсәтү);
- Торак пункт территориясен төзекләндерү (тракторчыга механикалаштырылган кар җыю буенча хезмәтләр өчен түләү, торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге юлларны тоту буенча чит оешмалар хезмәтләре өчен түләү, килешү буенча эшләр өчен түләү, Балан- Бүләк торак пунктында үлән чабу хезмәтләре өчен түләү, корыган агачлардан һәм куаклардан чистарту, килешү буенча эш һәм хезмәт күрсәтүләргә түләү)

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Чалпы авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Чалпы авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Чалпы авыл җирлеге башлыгы ____________ А.М.Мөхәмәтшин

(имза) (имза расшифровкасы)